**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында» Указына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында» 2014 елның 12 июнендәге ПУ-569 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 27 июнендәге ПУ-604 номерлы, 2015 елның 19 ноябрендәге ПУ-1111 номерлы, 2015 елның 19 декабрендәге ПУ-1228 номерлы, 2017 елның 15 сентябрендәге ПУ-818 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2018 елның 21 сентябрендәге ПУ-679 номерлы, 2019 елның 18 мартындагы ПУ-172 номерлы, 2020 елның 24 апрелендәге ПУ-252 номерлы һәм 2022 елның 15 декабрендәге ПУ-879 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы»;

б) 1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында нигезләмә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында нигезләмә» сүзләренә алмаштырырга;

г) Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында нигезләмәдә:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында нигезләмә»;

1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Россия Федерациясе Конституциясе,» сүзләреннән соң «федераль конституциячел законнар,» сүзләрен өстәргә;

3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта:

«а» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Татарстан Республикасы Рәисенә дәүләт һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү турында тәкъдимнәр әзерләү;»;

«е» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

«ж» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

«з» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

«к$^{1}$» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

«л» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

«н» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның «д» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты Администрациясенең белешмәләр банкы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең мәгълүмат системасы» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Совет эшчәнлеге Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты һәм Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе тарафыннан тәэмин ителә.»;

д) Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы составында:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы составы»;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ә.Ә. Сәфәровның – «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Совет рәисе»;

А.Н. Беловның – «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе, Советның җаваплы секретаре»;

М.С. Бәдретдиновның – «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы»;

И.М. Гариповның – «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы»;

Л.Ю. Глухованың – «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы»;

И.В. Терентьеваның – «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең Ветераннар советы рәисе».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 18 апрель
№ 241